ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Советская, д.1а, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

Совет ур., 1 нче а йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР

22.11.2018 ел № 24

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән «18» ноябрь 2018 елдагы № 923 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Уразбахты авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесе Р.Г.Шәйхетдинов

Татарстан
республикасы
Мамадыш муниципаль
районы,Уразбахты
авыл җирлеге
башкарма
комитетының 2018
елның 22 ноябрь 24№
лы карарына 1 нче
кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы,
Уразбахты авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Уразбахты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2019 нчы елнын 28 нче февраленә кадәр, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а)эшкә вакытлыча яраксызлык,

б)эш максатында командировка,

гражданнарга гариза нигезендә бер айдан артык булмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарынамуниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында,Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгаруһәм халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыуставында бигеләнгән тәртиптә,шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыруяки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан
Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Уразбахты
авыл җирлеге
башкарма
комитетының 2018
елның 22 ноябрь 24№
лы карарына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында

БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
______________________________________________________________________

Адрес:

Нигезләмә: Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 нче елның 19 нчы ноябрь 923 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге территориясендә 2018 нче елның 18 нче ноябрендә җирле референдум үткәрү нәтиҗәләре турында” карары нигезендә Сезгә 2019 нчы елның 28 нче февраленә кадәрге вакыт эчендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге территориясендә 2018 нче елның 18 нче ноябрендә үткән җирле референдум чараларын гамәлгә ашыру буенча 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы БИК 049205001
Сч. № ___________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № 40101810800000010001
ИНН 1626008921
КПП 162601001
КБК 60511714030100000180 ОКТМО 92638484
Түләүнең билгеләнеше: Гражданнарның үзара салым акчалары

Җитәкче __________________ Р.Г.Шәйхетдинов.
П.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне _________________ сум күләмендә түләү турында № _________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и.

__________________________________________________________

Адрес:

__________________________________________________________

Кабул ителде «__» ________________ 20__ ел.

________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*